**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р №20**

Мөслим «14» декабрь 2020 ел

**«2019 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында» 2019 елның 20 февралендәге 134 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 32 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районы Советының «2019 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында» 2019 елның 20 февралендәге 134 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2019 елга Мөслим муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) кушымтасыннан Татарстан Республикасы, Мөслим районы Мөслим авылы, Гагарин урамы, 9 а йорт адресы буенча урнашкан 317.9 кв. м. гомуми мәйданлы 1 катлы 1972 елда төзелгән йогышлы авырулар хастаханәсе бинасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин